| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ СПАССКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>СПАС МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОН СОВЕТЫ |

**Р Е Ш Е Н И Е** **К А Р А Р**

**5 июнь 2023 ел** Болгар ш. **№ 30-1**

Татарстан Республикасы муниципаль районы Советының 2021 елның 27 сентябрендәге 12-1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы "Спас муниципаль районы" муниципаль берәмлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (2022 елның 25 апрелендәге 19-2 номерлы;2023 елның 06 февралендәге 26-1 номерлы; 2023 елның 27 мартындагы 28-1 номерлы үзгәрешләр белән)

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $142^3$ статьясы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Инфраструктураны бергәләп үстерү өчен төбәкара һәм муниципальара хезмәттәшлек турында килешүләр төзү тәртибенә гомуми таләпләрне раслау турында» 2023 елның 6 февралендәге 167 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Советының 2021 елның 27 сентябрендәге 12-1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы "Спас муниципаль районы" муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында Нигезләмәгә (2022 елның 25 апрелендәге 19-2 номерлы;2023 елның 06 февралендәге 26-1 номерлы; 2023 елның 27 мартындагы 28-1 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 33 статьясының 1 пунктында «җирле әһәмияттәге» сүзләрдән соң: «шул исәптән, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләргә ярашлы рәвештә район Уставы һәм (яисә) район Советының норматив хокукый актлары белән билгеләнә торган шәһәр округы ягы булган инфраструктураны уртак үстерү өчен муниципальара хезмәттәшлек турында төзелгән килешүләрне гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында», - дип тулыландырырга.

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында http://www.spasskiy.tatarstan.ru һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны финанс-бюджет мәсьәләләре, икътисад һәм җирдән файдалану буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Спас муниципаль районы Башлыгы,
Советы Рәисе Ф. В. Мөхәммәтов